СОВЕТ
МЕНЗЕЛИНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНЗӘЛӘ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
СОВЕТЫ

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

30 декабрь 2019 ел. г.Мензелинск № 1

Татарстан Республикасы Минзәлә муниципаль районының
Җир һәм милек мөнәсәбәтләре палатасы турындагы
Нигезләмәне раслау хакында

“Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында” 06.10.2003 елдагы 131 номерлы Федераль Законы, Татарстан Республикасы Минзәлә муниципаль районы Уставы нигезендә, Татарстан Республикасы Минзәлә муниципаль район Советы КАРАР БИРДЕ:

1. Минзәлә муниципаль районының Җир һәм милек мөнәсәбәтләре палатасын булдырырга һәм аңа юридик зат хокукларын бирергә.
2. Минзәлә муниципаль районының Җир һәм милек мөнәсәбәтләре палатасы турында беркетелгән Нигезләмәне расларга.
3. Минзәлә муниципаль районының Җир һәм милек мөнәсәбәтләре палатасы рәисе итеп Садыйков Роберт Садиковичны билгеләргә.
4. Минзәлә муниципаль районы Җир һәм милек мөнәсәбәтләре палатасының гамәлгә кую документларына дәүләт теркәве буенча чаралар уздыру вәкаләтләрен Минзәлә муниципаль районының Җир һәм милек мөнәсәбәтләре палатасы рәисенә бирергә.
5. Әлеге карар рәсми төстә басылырга тиеш.
6. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны икътисад, бюджет һәм эшмәкәрлек буенча даими комиссиягә йөкләргә.

Совет рәисе А.Ф. Сәлахов

Татарстан Республикасы
Минзәлә муниципаль район Советы
карарына
Кушымта
дата 30.12.2019 № 1

# МИНЗӘЛӘ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ ҖИР ҺӘМ МИЛЕК МӨНӘСӘБӘТЛӘРЕ ПАЛАТАСЫ ТУРЫНДА НИГЕЗЛӘМӘ

## 1. Гомуми нигезләмәләр

1.1. Минзәлә муниципаль районы Җир һәм милек мөнәсәбәтләре палатасы (алга таба – Палата) үз вәкаләтләре чикләрендә муниципаль милек, шул исәптән, җир кишәрлекләре, акцияләр, хуҗалык җәмгыятьләренең устав капиталларында өлешләр (кертемнәр) белән идарә итүне гамәлгә ашыручы муниципаль район Башкарма комитетының даими (функциональ) гамәлдә булган тармак органы булып тора.

1.2. Палата муниципаль казна учреждениесе формасында юридик зат булып тора һәм дәүләт теркәве узарга тиеш..
Тулы атамасы – “Татарстан Республикасы Минзәлә муниципаль районының Җир һәм милек мөнәсәбәтләре палатасы” муниципаль казна учреждениесе.

Кыскартылган атамасы – “Минзәлә муниципаль районының Җир һәм милек мөнәсәбәтләре палатасы” МКУ.

Әлеге Нигезләмәдә һәм башка муниципаль хокукый актларда “Минзәлә муниципаль районы Җир һәм милек мөнәсәбәтләре палатасы” муниципаль казна учреждениесе”, “Минзәлә муниципаль районы Җир һәм милек мөнәсәбәтләре палатасы” МКУ, “Минзәлә муниципаль районы Җир һәм милек мөнәсәбәтләре палатасы”, “Минзәлә муниципаль районы Җир һәм милек мөнәсәбәтләре палатасы” сүзләре һәм алар нигезендә барлыкка килгән сүзтезмәләр бер мәгънәдә кулланыла.

1.3. Палата үз вәкаләтләрен гамәлгә ашырганда район Советына, район Башлыгына һәм район Башкарма комитеты Җитәкчесенә отчет бирә.

Палата үз эшчәнлеген законнар, “Минзәлә муниципаль районы” муниципаль берәмлеге Уставы, әлеге Нигезләмә нигезендә гамәлгә ашыра.

1.4. Палатаның мөһере, Минзәлә муниципаль районы Гербы төшерелгән һәм үз атамасы белән штамплары, лицевой счетлары бар.

1.5. Палатаның юридик һәм почта адресы: 423700, ТР, Минзәлә шәһәре, Ленин ур., 80 нче йорт.

1.6. Палата Татарстан Республикасы Минзәлә муниципаль районының Финанс-бюджет һәм җир-милек палатасының хокук күчемлелегенә ия булучысы булып тора.

1.7. Палата башка юридик һәм физик затлар белән үз исеменнән хокукый

мөнәсәбәтләргә керә ала.

1.8. Палатаның структурасы һәм штат расписаниесе муниципаль район җирле үзидарә башкарма органнары хезмәткәрләре саны һәм хезмәткә түләү фонды чикләрендә район Советы тарафыннан раслана.

1.9. Палата тарафыннан әзерләнгән карарлар билгеләнгән тәртиптә Палата Рәисенең күрсәтмәләре, боерыклары рәвешендә рәсмиләштерелә.

**2. Палата бурычлары**

Палатаның төп бурычлары түбәндәгеләр:

2.1. Билгеләнгән тәртиптә милек, шул исәптән, муниципаль хосусыйлыкта булган җир ресурсларын биләү, файдалану һәм идарә итү.

2.2. Муниципаль милектән файдаланудан максималь файда алу һәм керемлелекне тәэмин итү.

2.3. Күчемле һәм күчемсез милектән файдалануны контрольдә тотуны тәэмин итү.

**3. Палатаның төп функцияләре**

Төп бурычларны хәл итү кысаларында Палата үз компетенциясе кысаларында түбәндәге функцияләрне башкара:

3.1. Муниципаль милек белән идарә итү, биләү һәм эш итүне билгеләнгән тәртиптә гамәлгә ашыра.

3.2. Муниципаль районның норматив хокукый актлары нигезендә муниципаль милекне арендага бирү, аны ышанычлы идарәгә, түләүсез ашыгыч файдалануга тапшыру турында карарлар кабул итә.

3.3. Муниципаль хосусыйлыкта булган муниципаль милекне һәм җир кишәрлекләрен сатучы функцияләрен билгеләнгән законлы тәртиптә башкара. Махсуслаштырылган оешмалар белән сату (конкурс, аукцион) уздыру турында шартнамәләр төзи, приватизация объектларын махсуслаштырылган оешмаларга сату өчен билгеләнгән тәртиптә тапшыра.

3.4. Россия Федерациясе Хөкүмәтенең башкарма хакимияте федераль органының вәкиле билгеләгән Тәртиптә районның муниципаль милеге реестрын алып бара.

3.5. Муниципаль милекне, шул исәптән, җир кишәрлекләрен федераль хосусыйлыкка, Татарстан Республикасы хосусыйлыгына, башка муниципаль берәмлекләр һәм хосусыйлыкның башка формаларына хосусыйлыкка тапшыруны гамәлгә ашыра.

3.6. Җир кишәрлекләрен муниципаль һәм дәүләт учреждениеләренә, даими (сроксыз) файдалану хокукында җирле үзидарә һәм дәүләт хакимияте органнарына, муниципаль унитар предприятиеләргә арендага тапшыруны гамәлгә ашыра.

3.7. Җир кишәрлекләре белән идарә итү (арендага һәм хосусыйлыкка тапшыру) турында карар кабул итә:

- дәүләт хакимиятенең һәм идарәсенең җирле органнарына, унитар предприятиеләргә, учреждениеләргә, дәүләт хакимиятенең һәм идарәсенең җирле органнары тарафыннан булдырылган коммерциягә кагылмаган башка оешмаларга тапшырылган;

- приватизацияләү турында карар дәүләт хакимиятенең һәм идарәсенең җирле органнары тарафыннан кабул ителгән күчемсез приватизацияләнгән милек биләгән;

- Татарстан Республикасының резерв фонды составына кергән җирләрдән тыш, шул исәптән, шәхси торак төзелешен һәм шәхси ярдәмче хуҗалык алып бару өчен җирлекләр җирләреннән бушаган җир кишәрлекләре;

- идарә итү хокукы законнар нигезендә муниципаль район вәкаләтләренә карый.

3.8. Авыл хуҗалыгы билгеләнешендәге җирләрдән җир кишәрлекләрен сату турында хәбәрнамәне закон нигезендә тикшерә һәм җир кишәрлекләрен муниципаль хосусыйлыкка сатып алу, шулай ук аларны сатып алудан баш тарту турында карарлар кабул итә.

3.9. Башкарма комитет карарлары нигезендә җир кишәрлекләрен, шул исәптән муниципаль ихтыяҗлар өчен билгеләнгән тәртиптә тартып алынган, шулай ук башка милекне муниципаль хосусыйлыкка ала.

3.10. “Авыл хуҗалыгы билгеләнешендәге җирләрнең әйләнеше турында”гы Федераль законда, Татарстан Республикасының Җир кодексында каралган очракларда һәм тәртиптә тиешле гаризалар белән судка мөрәҗәгать итә.

3.11. Муниципаль җир контролен башкара.

3.12. Үз компетенциясе чикләрендә муниципаль хосусыйлыкта булган җир кишәрлекләре белән идарә итү һәм җир реформасын уздыру белән бәйле эшләрнең заказ бирүчесе булып тора, аларның үтәлешенә конкурс нигезендә заказлар урнаштыра.

3.13. Закон белән билгеләнгән тәртиптә, район Советы карарлары нигезендә булдырылган муниципаль унитар предприятиеләрнең гамәлгә куючысы булып тора.

3.14.Муниципаль унитар предприятиеләргә аларның устав бурычларын башкару өчен кирәкле милекнең оптималь күләмен билгели.

3.15. Муниципаль хосусыйлыкта булган милекне, шул исәптән социаль-мәдәни өлкә объектларын муниципаль унитар предприятиеләрнең хуҗалык биләвенә беркетә.

3.16. Муниципаль унитар предприятиеләргә билгеләнгән тәртиптә түбәндәгеләргә ризалык бирә:

- күчемсез милекне читләштерү һәм аның белән идарә итү шул исәптән залогка, арендага, милек кертемнәрен оешмаларның устав (берләштерелгән) капиталына кертү, шулай ук федераль законнар һәм башка норматив хокукый актлар яик предприятие уставы нигезендә каралган очракларда, башка килешүләр башкаруга;

- кызыксындыру тудырырлык эре килешүләрне гамәлгә ашыру;

- заемнар, җаваплылыкны үз өстенә алу, банк гарантияләрен алу, башка

читләштерү, бурычны күчерү таләпләренә юл кую, шулай ук гади ширкәтнең килешүләр төзүе белән бәйле килешүләрне гамәлгә ашыру;

- предприятиенең башка юридик затларда катнашуы;
- филиаллар булдыру һәм вәкиллекләр ачу.

Муниципаль унитар предприятиеләргә үзләштерүләр күләмен һәм җәлеп ителә торган чаралардан файдалану юнәлешләрен килешенә.

3.17. Муниципаль хосусыйлыкта булган милекне муниципаль учреждениеләрнең оператив идарәсенә беркетә, шулай ук оператив идарәгә беркетелгән, файдаланылмый торган яки билгеләнеше буенча файдаланылмый торган, артык милекне билгеләнгән тәртиптә тартып алуны башкара.

3.18. Билгеләнгән тәртиптә башка затларга тапшырылган, муниципаль учреждениеләрне һәм муниципаль унитар предприятиеләрне башка идарәгә яки хуҗалык биләвенә беркетелгән җир кишәрлекләрен һәм башка муниципаль милекнең сакланышына һәм идарә итүгә, биләүгә, эш итүгә, билгеләнеше буенча файдалануына контрольне гамәлгә ашыра, һәм ачыкланган очракта, Россия Федерациясе, Татарстан Республикасы законнары нигезендә аларны бетерү һәм җаваплы затларны җаваплылыкка тарту өчен тиешле чаралар күрә.

3.19. Үз компетенциясе чикләрендә муниципаль хосусыйлык объектларына инвентаризация, муниципаль милекнең сакланышы һәм нәтиҗәле файдаланышы мәсьәләләре буенча юридик затларга документаль һәм башка тикшерүләр билгели һәм уздыра.

3.20. Төп фондларны, шулай ук муниципаль унитар предприятиеләрнең, муниципаль учреждениеләрнең оператив идарәсендә хуҗалык итү хокукында булган объектларның туктатылган яки (и) башкарылмаган төзелеше буенча чыгымнарны төшереп калдыруны гамәлгә ашыра һәм контрольдә тота.

3.21. Муниципаль унитар предприятиеләргә карата, шул исәптән кабаттан оештыру, ликвидацияләүдә карарлар кабул итә.

Россия Федерациясе һәм Татарстан Республикасы законнары кысаларында устав капиталларында муниципаль район өлеше булган акционерлык җәмгыятьләренең ярлылыгы процедураларын уздыруны тәэмин итә.

3.22. Муниципаль унитар предприятиеләрнең һәм устав капиталларында муниципаль район өлеше булган акционерлык җәмгыятьләре һәм муниципаль унитар предприятиеләрнең ярлылыгын (банкротлылык) булдырмау, кризиска каршы идарә итү буенча чараларны эшкәртү һәм гамәлгә ашыруда катнаша.

3.23. Башкарма комитет карарлары нигезендә тиешле елга муниципаль милекне приватизацияләүнең фаразланган план (программа) проектын эшкәртә.

3.24. Муниципаль унитар предприятиеләрне һәм башка объектларны приватизацияләүгә әзерләү буенча чараларны гамәлгә ашыра.

Приватизацияләнүче муниципаль милекнең бәясен билгеләү уздыруны оештыра. Билгеләнгән бәяне раслый һәм приватизацияләнүче предприятиеләрнең устав капиталы зурлыгын билгели.

3.25. Муниципаль милекне приватизацияләүнең фаразланган план (программа) нигезендә муниципаль милекне (акцияләр, өлешләр, пайлар,

предприятиеләрнең милек комплекслары) приватизацияләү, шул исәптән, хуҗалык җәмгыятьләренең устав капиталларына кертем сыйфатында аны кертү турында, муниципаль милекне приватизацияләү, приватизация планнарын раслау шартлары турында карарлар кабул итә.

3.26. Муниципаль милекне приватизацияләү турында, шулай ук приватизация килешүләре нәтиҗәләре турында массакүләм мәгълүмат чараларында бастыруны тәэмин итә.

3.27. Ачык акционерлык җәмгыятьләренең, шул исәптән, приватизация барышында булдырылган муниципаль унитар предприятиеләрнең гамәлгә куючысы (катнашучысы) буларак муниципаль район исеменнән, шулай ук Россия Федерациясе законнары нигезендә башка юридик затлар муниципаль район катнашында гамәлгә куючы исеменнән чыгыш ясый.

Муниципаль милекне приватизацияләү барышында булдырылган хуҗалык җәмгыятьләре уставын раслый.

3.28. Законнар нигезендә акционерлык җәмгыятьләренең (хуҗалык җәмгыятьләренең), муниципаль хосусыйлыкта булган акцияләрнең (устав капиталында өлешләре) акционерлык (катнашучы) хокукын гамәлгә ашыра.

3.29. Башкарма комитетка. Район Советына, Татарстан Республикасының җир һәм милек мөнәсәбәтләре буенча вәкаләтле органга узган ел өчен муниципаль милекне приватизацияләү нәтиҗәләре турында отчет әзерли һәм тапшыра.

3.30. Үз компетенциясе чикләрендә акционерларның гомуми җыелышларында сайлау өчен устав капиталында муниципаль район өлешләре белән хуҗалык җәмгыятьләренең идарә һәм контроль органнарына муниципаль район вәкилләренә кандидатураларны күрсәтә. Аларны укытуны, җитәкчелек итүне, методик тәэмин ителешен һәм эшчәнлеген контрольдә тотуны оештыра.

3.31. Законда каралган очракларда муниципаль район вәкилләренә хуҗалык җәмгыятьләренең идарә органнарында карарлар проектларын һәм аларга тавыш бирүне билгеләнгән тәртиптә килешенә. Хуҗалык җәмгыятьләре идарәсе мәсьәләләре буенча тавыш биргәндә позицияне килешенү буенча муниципаль район вәкилләре тарафыннан үтәлешен контрольдә тота.

3.32. Татарстан Республикасында торак сәясәтен торак фондының күчемсез милек идарәсе системасын булдыру, шул исәптән, муниципаль хосусыйлыкта булган күпфатирлы йортларда торак бүлмәләр һәм тәмамланмаган төзелеш объектларын эшкәртү һәм гамәлгә ашыруда катнаша.

Социаль наем килешүләре буенча гражданнарга тапшырылган күпфатирлы йортларда торак бүлмәләрне муниципаль учетка алу системасын оештыра, алар белән идарә итү механизмнарын эшкәртә.

Белем бирү һәм милек хуҗалары ширкәте эшчәнлеге өчен имин шартлар тудыруга булыша.

Муниципаль хосусыйлыкта булган торак фонды объектларын хуҗалык карамагына, оператив идарәгә, түләүсез файдалануга һәм махсуслаштырылган һәм идарәче оешмаларга башка төр идарәгә тапшыра.

3.33. Муниципаль торак фондын приватизацияләүне башкара.

3.34. Җирле үзидарә органнарына приватизацияләүдән калган чараларның керүе, муниципаль милектән, шул исәптән җир ресурсларыннан файдалану турында билгеләнгән тәртиптә җирле үзидарәнең тиешле органнарына эшкәртә һәм тапшыра.

3.35. Дивидендларның оптималь күләмен билгели. Акционерлык җәмгыятьләренең (башка хуҗалык җәмгыятьләренең устав капиталында өлешләр буенча керемнәр) муниципаль хосусыйлыгында булган акцияләре буенча дивидентларны җирле бюджетка күчүен контрольдә тота һәм чаралар күрә.

3.36. Муниципаль унитар предприятиеләрнең чиста табышының бер өлешен җирле бюджетка күчерүне оештыра.

Сату һәм арендалаудан, шулай ук муниципаль милектән, шул исәптән, муниципаль хосусыйлыкта булган җир кишәрлекләреннән башкача файдаланудан җирле бюджетка чаралар керүен контрольгә ала.

3.37. Муниципаль милектән, шул исәптән, җир ресурсларыннан файдаланган өчен аренда түләве күләмен билгеләү буенча район Советына тәкъдимнәр эшкәртә һәм кертә.

3.38. Муниципаль унитар предприятие җитәкчеләре белән хезмәт килешүләрен билгеләнгән тәртиптә төзи, үзгәртә һәм өзә.

3.39. Муниципаль милеккә карата милек хокукларын һәм муниципаль берәмлек вәкаләтләрен яклауны үз компетенциясе чикләрендә муниципаль район исеменнән тәэмин итә.

3.40. Ярлылык (банкротлык), шул исәптән, ярлылыкны (банкротлык) башлап җибәрү турында, шулай ук муниципаль берәмлекнең өлеше (кертем) устав (берләштерелгән) капиталларда, хуҗалык берләшмәләрендә һәм муниципаль унитар предприятиеләргә карата милекче буларак муниципаль районның законлы мәнфәгатьләрен банкротлык процедураларында хәл иткәндә күрсәтә.

3.41. Федераль законнар һәм Татарстан Республикасы законнары нигезендә, муниципаль районның җирле үзидарә органнарына тапшырылган дәүләт милеге һәм җир ресурслары белән идарә итү өлкәсендә аерым дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыра.

3.42. Палатага йөкләнгән вәкаләтләр чикләрендә башка функцияләр башкара.

**4. Палатаның хокуклары һәм бурычлары**

4.1. Палата түбәндәге хокукларга ия:

4.1.1. Үз исеменнән килешүләр төзергә, закон белән билгеләнгән тәртиптә милек һәм милек булмаган хокуклар алырга, йөкләмәләрне үтәргә, дәгъвачы була һәм судта җавапчы була ала.

4.1.2. Устав капиталларында муниципаль берәмлек өлеше булган акционерлык җәмгыятьләренең директорлар советы һәм акционерлар җыелышларының көн тәртибенә тәкъдимнәр җибәрергә, аларны уздыруга контрольне гамәлгә ашырырга.

4.1.3. Татарстан Республикасы дәүләт хакимиятенең башкарма

органнарыннан, муниципаль унитар предприятиеләрдән һәм муниципаль учреждениеләрдән, җирле үзидарә органнарыннан, муниципаль район территориясендә урнашкан башка оешмалардан законда каралган икътисадый, статистик, хокукый һәм Палатага йөкләнгән бурычларны үтәү өчен кирәкле башка мәгълүматне бушлай алырга.

4.1.4. Дәүләт теркәве, кадастр һәм картография органнарыннан түләүсез нигездә закон белән билгеләнгән тәртиптә җир кишәрлекләренә һәм күчемсез милек объектларына хокуклар һәм аларны сату-алу килешүләре турында һәм муниципаль хосусыйлыкта булган булган җирләр белән идарә итүне оештыру, муниципаль милекне учетка алу һәм аның реестрын алып бару өчен кирәкле башка мәгълүматларны соратып алырга һәм алырга.

4.1.5. Муниципаль район исеменнән приватизация, идарә итү һәм муниципаль милек белән эш итү мәсьәләләре буенча муниципаль районны яклап дәгъвалар (гаризалар) белән судка мөрәҗәгать итәргә, шул исәптән:

приватизация һәм муниципаль милек белән идарә итү буенча килешүләрнең гамәлдә булмавын тану;

муниципаль унитар предприятиеләрнең табышы өлешендә түләтүләр;

муниципаль милектән, шул исәптән, җир кишәрлекләреннән файдаланган өчен аренда һәм башка түләүләрне түләтү;

физик һәм (яки) юридик затларның хокуксыз гамәлләре белән муниципалҗ берәмлеккә килгән зыянны һәм башка зыянны түләтү;

законда каралган очракларда, башка мәсьәләләр буенча.

4.1.6. Хуҗалык итү, оператив, ышанычлы идарә хокукларында оешмаларга беркетелгән муниципаль милекне законда билгеләнгән очракларда һәм тәртиптә тартып алу.

4.1.7. Дәүләт хакимияте органнарына мөрәҗәгать итәргә:

муниципаль район җирле үзидарә органнарының норматив хокукый актлары проектларын, җир һәм милек мөнәсәбәтләре өлкәсендә методик материалларны, рекомендацияләрне, инструкцияләрне эшкәрткәндә методик һәм практик ярдәмне түләүсез алу мәсьәләләре буенча;

Татарстан Республикасы дәүләт хосусыйлыгы объектларын муниципаль район хосусыйлыгына тапшыру буенча тәкъдимнәр белән.

4.2. Палата бурычлы:

4.2.1. Үз компетенциясе чикләрендә, муниципаль районның икътисадый мәнфәгатьләренә зыян салмыйча, муниципаль милек һәм җир ресурслары белән нәтиҗәле идарә итәргә.

4.2.2. Муниципаль милекне приватизацияләгәндә закон бозылган очракларда, муниципаль милекне приватизацияләү килешүләрен өзү, зыянны каплау һәм муниципаль милекне сату-алу килешүләре һәм законнар нигезендә башка чаралар куллану турында дәгъваларны суд тәртибендә белдерергә.

4.2.3. Гаеплеләрне җаваплылыкка тарту турында карар кабул итү өчен җир мөнәсәбәтләре белән бәйле мәсьәләләр буенча муниципаль милекне биләү, файдалану һәм идарә итү өлкәсендә законны бозу турындагы материалларны хокук

саклау органнарына билгеләнгән тәртиптә җибәрергә.

4.2.4. Үз эшчәнлеге турында отчетларны һәм мәгълүматны район Советына, район Башкарма комитетына, Татарстан Республикасының дәүләт хакимияте органнарына законнар белән билгеләнгән тәртиптә тапшырырга.

**5. Палата эшчәнлеген оештыру**

5.1. Палатаны гамәлдәге законнар нигезендә төзелә торган хезмәт килешүе (контракт) буенча район Башлыгы тәкъдиме буенча район Башкарма комитеты җитәкчесе тарафыннан вазыйфага билгеләнә һәм азат ителә торган рәис җитәкли.

5.2. Палата рәисе конкурс нигезендә билгеләнә торган муниципаль районның җирле үзидарәсе вазыйфаи заты булып тора.

Палата рәисе:

Палата исеменнән ышаныч язуыннан башка эш итә, барлык учреждениеләрдә һәм оешмаларда, судларда аның мәнфәгатьләрен яклый, Палата хезмәткәрләре мәҗбүри үтәргә тиеш боерыклар, күрсәтмәләр чыгара, эчке документларны раслый;

Палата исеменнән шартнамәләр, контрактлар, килешүләр һәм башка килешенүләр төзи, аларның үтәлешен тәэмин итә;

банкларда хисап һәм башка счетлар ача, алар буенча операцияләр башкара, финанс документларын имазлый;

хезмәткә түләү фонды чикләрендә Палатаның структурасын һәм штат расписаниесен район Башкарма комитетына раслауга тапшыра;

бер генә кеше идарәсе нигезендә Палата эшчәнлеге белән гомуми җитәкчелекне башкара һәм вәкаләтле органга йөкләнгән функцияләрнең үтәлеше өчен персональ җаваплылык тоа;

Палата белгечләре арасында бурычларны бүлеп бирә һәм эшләүчеләрнең вазыйфаи инструкцияләрен раслый;

Палатада эшләүчеләргә бүләкләү чараларын куллана һәм гамәлдәге законнар нигезендә аларга шелтә белдерә;

үз компетенциясе чикләрендә күрсәтмәләр һәм боерыкнамәләр бирә;

Палатага тапшырылган милекнең исәбен һәм сакланышын оештыра;

Палата хезмәткәрләрен эшкә ала һәм эштән азат итә;

гражданнарны кабул итә, аларның тәкъдимнәрен, гаризаларын, дәгъваларын тикшерә;

Палат функцияләреннән чыгучы башка вәкаләтләр башкара.

**6. Палата милеге**

6.1. Беркетелгән төп һәм әйләнештәге чаралар Палата милеге булып санала.

6.2. Палата эшчәнлеген финанслау җирле үзидарә органнарын карап тотуга бүленә торган чыгымнарның еллык сметасы чикләрендә җирле бюджет хисабыннан гамәлгә ашырыла.

**7. Палата хезмәткәрләрен социаль яклау**

7.1. Палатада эшләүчеләр муниципаль хезмәткәрләр булып тора.

7.2. Палатада эшләүчеләргә социаль гарантияләр муниципаль хезмәт турында законнар нигезендә тәэмин ителә.